**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасы Президентының Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре һәм Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләү мәсьәләләре буенча аерым указларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2016 елның 18 мартындагы 11-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы кабул ителү һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм шәхси эшкуарлар коллективларын бүләкләү системасын камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Кушымтада бирелгән исемлек буенча Татарстан Республикасы Президенты указларына үзгәрешләр кертергә.

2. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты турында» 2003 елның 12 мартындагы ПУ-200 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты турында нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында» 2003 елның 11 июнендәге ПУ-432 номерлы Указы;

Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының аерым указларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 16 мартындагы ПУ-126 номерлы Указының 1 пункты;

«Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-874 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы.

3. Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсенә Татарстан Республикасы Президенты актларын әлеге Указга туры китерү буенча тәкъдимнәрен бирергә.

4. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** — **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ · ГОМУМИ БҮЛЕК · ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2016 ел, 12 август
№ ПУ-684

Татарстан Республикасы
Президентының
2016 елның « 12 » августындагы
ПУ-684 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасы Президенты указларына кертелә торган үзгәрешләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә таныклыклар формасын (үрнәкләрен) раслау турында» 2010 елның 22 июнендәге ПУ-396 номерлы Указында (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-875 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән):

а) атамасында «бүләкләү кәгазе формасын» сүзләрен «бүләкләү кәгазе формаларын» сүзләренә алмаштырырга;

б) преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законының 29 һәм 37 статьялары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 18 һәм 26 статьялары» сүзләренә алмаштырырга;

в) 1 пунктның икенче һәм өченче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә таныклыклар формаларын (үрнәкләрен) (1 нче, $1^1$ нче һәм 2 нче кушымталар);

бүләкләү кәгазе формаларын (3 нче һәм 4 нче кушымталар).»;

г) 1 нче кушымтада:

атамасына сноскада «бүләкләү» сүзеннән соң «гражданны», «ордены,» сүзеннән соң – «ордены медале» сүзләрен өстәргә;

унберенче абзацта «6 өстәмә битле бланк» сүзләрен «8 өстәмә битле бланк» сүзләренә алмаштырырга;

соңгы абзацта «алтынчы битендә» сүзләрен «алтынчы, җиденче һәм сигезенче битләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

д) әлеге Исемлеккә 1 нче кушымта нигезендә $1^1$ нче кушымта өстәргә;

е) 2 нче кушымтада:

унберенче абзацта «6 өстәмә битле бланк» сүзләрен «8 өстәмә битле бланк» сүзләренә алмаштырырга;

соңгы абзацта «алтынчы битендә» сүзләрен «алтынчы, җиденче һәм сигезенче битләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

ж) 3 нче кушымтада:

атамасында «бүләкләү» сүзеннән соң «гражданны» сүзен өстәргә;

6 пунктта «уку йорты» сүзләрен «мәгариф оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «әлеге коллективта» сүзләрен «вазыйфада» сүзенә алмаштырырга;

текст буенча «Бәяләмә» сүзен «Бәяләмә****» сүзенә алмаштырырга;

искәрмәләргә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«**** Бүләкләү кәгазе кәгазь чыганакта бирелгән очракта тутырыла.»;

з) әлеге Исемлеккә 2 нче кушымта нигезендә 4 нче кушымта өстәргә.

2. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Ана даны – Материнская слава» медале тасвирламасын, аңа таныклык формасын (үрнәген) һәм бүләкләү кәгазе формасын раслау турында» 2010 елның 22 июнендәге ПУ-397 номерлы Указында (Татарстан Республикасы Президентының 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-876 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәреше белән):

а) преамбулада «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законының 16, 29 һәм 37 статьялары» сүзләрен «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» 2011 елның 10 октябрендәге 74-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3, 18 һәм 26 статьялары» сүзләренә алмаштырырга;

б) 2 нче кушымтада:

унберенче абзацта «6 өстәмә битле бланк» сүзләрен «8 өстәмә битле бланк» сүзләренә алмаштырырга;

соңгы абзацта «алтынчы битендә» сүзләрен «алтынчы, җиденче һәм сигезенче битләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 нче кушымтада:

5 пунктта «уку йорты» сүзләрен «мәгариф оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

текст буенча «Бәяләмә» сүзен «Бәяләмә***» сүзенә алмаштырырга;

искәрмәләргә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«*** Бүләкләү кәгазе кәгазь чыганакта бирелгән очракта тутырыла.».

3. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-873 номерлы Указында:

а) преамбулада «гражданлыксыз,» сүзеннән соң «дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм оешмалар коллективларын,» сүзләрен өстәргә;

б) Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе турында нигезләмәдә:

2 пунктта «(алга таба – гражданнар)» сүзләреннән соң «һәм дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары (алга таба шулай ук – органнар), оештыру-хокукый формаларына һәм милек формаларына карамастан, оешмалар, шәхси эшкуарлар (алга таба – оешмалар) коллективлары» сүзләрен өстәргә;

4 пунктта:

«а» пунктчасында «хезмәткәрләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасында «хезмәткәрләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

«в» пунктчасында «җитәкчеләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) үз эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә тормышка ашырмаучы оешмалар хезмәткәрләренә, шәхси эшкуарлар хезмәткәрләренә (алга таба – оешмалар хезмәткәрләренә), шәхси эшкуарларга, оешмалар коллективларына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты оештырган сәүдә-икътисадый (сәүдә) вәкиллекләре хезмәткәрләреннән һәм коллективларыннан тыш).»;

5 пунктта:

«а» пунктчасында «хезмәткәрләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

«б» пунктчасында «хезмәткәрләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

«г» пунктчасында «хезмәткәрләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

«д» пунктчасында «хезмәткәрләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

«е» пунктчасында «4 һәм 6 пунктларында» сүзләрен «4, 6 һәм 7 пунктларында» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «хезмәткәрләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

7 пунктта «хезмәткәрләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

8 пунктта:

«җәмәгать берләшмәләре» сүзләреннән соң «(гражданнарга карата)» сүзләрен өстәргә;

«хезмәткәрләренә» сүзеннән соң «һәм коллективларына» сүзләрен өстәргә;

10 һәм 11 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10. Үтенечнамәдә гражданнар яисә органнар һәм оешмалар коллективларының әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары (ирешкән уңышлары) турында мәгълүмат булырга тиеш.

11. Гражданны бүләкләү турында үтенечнамәгә әлеге Нигезләмәгә 1 нче кушымта итеп бирелүче форма буенча гариза кәгазе һәм әлеге Нигезләмәгә 2 нче кушымтадагы исемлек буенча документлар теркәлә.

Органнар һәм оешмалар коллективларын бүләкләү турында үтенечнамәгә әлеге Нигезләмәгә 3 нче кушымта итеп бирелүче форма буенча гариза кәгазе һәм әлеге Нигезләмәгә 4 нче кушымтадагы исемлек буенча документлар теркәлә.

Үтенечнамәгә гражданның яисә органнар һәм оешмалар коллективларының Татарстан Республикасы алдындагы казанышларын

(ирешкән уңышларын) раслаучы башка документлар да кушып бирелергә мөмкин.»;

12 пунктның беренче абзацына «, шулай ук коллективлары Рәхмәт сүзе белән бүләкләнүгә тәкъдим ителүче орган яисә оешма атамасы нигезләмә, физик затны шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәве турында таныклык, устав, орган яисә оешманың башка гамәлгә кую документы нигезендә языла» сүзләрен өстәргә;

14 пунктның беренче абзацында «гражданның» сүзеннән соң «, орган яисә оешма коллективының» сүзләрен өстәргә;

15 пунктның «б» пунктчасына «, орган, оешма коллективларының» сүзләрен өстәргә;

17 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Тәкъдим итүдә гражданның, орган, оешма коллективының әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән Татарстан Республикасы алдындагы казанышлары (ирешкән уңышлары) турында мәгълүматлар булырга тиеш.»;

18 пунктта «2 нче кушымтада» сүзләреннән соң «(гражданны Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә тәкъдим иткәндә) яисә 4 нче кушымтада (орган, оешма коллективын Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә тәкъдим иткәндә)» сүзләрен өстәргә;

20 пунктка түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасы өстәргә:

«д) коллективлары Рәхмәт сүзе белән бүләкләнүгә тәкъдим ителгән орган, оешма үзгәртеп корылганда яисә бетерелгәндә.»;

24 пунктның беренче абзацында «гражданнар» сүзеннән соң «орган, оешма коллективлары,» сүзләрен өстәргә;

1 нче кушымтада:

атамасында «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе» сүзләренә кадәр «Гражданны» сүзен өстәргә;

6 пунктта «уку йорты» сүзләрен «мәгариф оешмасы» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктта «әлеге коллективта» сүзләрен «вазыйфада» сүзенә алмаштырырга;

текст буенча «Бәяләмә» сүзен «Бәяләмә***» сүзенә алмаштырырга;

искәрмәләргә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«*** Бүләкләү кәгазе кәгазь чыганакта бирелгән очракта тутырыла.».

2 нче кушымтада:

атамасында «Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе» сүзләренә кадәр «Гражданны» сүзен өстәргә;

5 пунктның беренче, икенче һәм өченче абзацларында «дәүләт идарәсе функцияләрен» сүзләрен «идарә функцияләре (функцияләрне җайга салу)» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «дәүләт идарәсе функцияләрен» сүзләрен «идарә функцияләре (функцияләрне җайга салу)» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 8 пункт өстәргә:

«8. Муниципаль берәмлек башлыкларын һәм җирле үзидарә органнары җитәкчеләрен Рәхмәт сүзе белән бүләкләү хакында үтенечнамә

кузгатылганда – тиешле муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше төп күрсәткечләре.»;

искәрмәләрнең өченче абзацында «6, 7» саннарын «6 - 8» саннарына алмаштырырга;

әлеге Исемлеккә 3 нче һәм 4 нче кушымталар нигезендә 3 нче һәм 4 нче кушымталар өстәргә;

в) Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе тасвирламасын әлеге Исемлеккә 5 нче кушымта нигезендәге редакциядә бәян итәргә.

4. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау хакында» 2011 елның 27 декабрендәге ПУ-875 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләү турындагы үтенечнамәләрне карау тәртибендә:

а) 1 пунктның беренче абзацында «(алга таба – гражданнар)» сүзләреннән соң «, оешмалар һәм аларның бүлекчәләре, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнарыннан (алга таба – оешмалар) тыш,»;

б) 2 пунктта:

«Үтенечнамәләр» сүзенә кадәр «гражданны бүләкләү турында» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Оешмаларны бүләкләү турында үтенечнамәләр эшчәнлекнең тиешле өлкәсендә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы республика башкарма хакимияте органнары тарафыннан кузгатыла.»;

в) 4 пунктның беренче абзацында «кушып бирелгән» сүзләрен «1 нче кушымтада (гражданны бүләкләү турында үтенечнамә кузгатканда) яисә 2 нче кушымтада (оешманы бүләкләү турында үтенечнамә кузгатканда)» сүзләренә алмаштырырга;

г) 6 пунктта:

«а» пунктчасында «үзенә карата үтенечнамә кузгатылган гражданның» сүзләрен «үзләренә карата үтенечнамә кузгатылган гражданның яисә оешманың» сүзләренә, «затларга» сүзләрен «гражданнарга яисә оешмаларга» сүзләренә алмаштырырга;

«в» пунктчасында «яисә оешмалар» сүзләрен өстәргә;

«г» пунктчасында «кушымтада» сүзен «1 нче кушымтада яисә 2 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

д) кушымтаны әлеге Исемлеккә 6 нчы кушымта нигезендәге редакциядә бәян итәргә;

е) әлеге Исемлеккә 7 нче кушымта нигезендә 2 нче кушымта өстәргә.

———

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Президентының
2010 елның 22 июнендәге
ПУ-396 номерлы Указына
$1^1$ нче кушымта

**Татарстан Республикасы дәүләт бүләгенә таныклык формасы (үрнәге)***

Таныклык 75 x 105 мм һәм ачып куйгач 150 x 105 мм зурлыктагы куе кызыл төстәге тире тышлыклы китапчыктан гыйбарәт.

Таныклык тышлыгының алгы ягындагы өске өлешендә Татарстан Республикасы Дәүләт гербының алтын сурәте төшерелгән, аның астында алтын хәрефләр белән төшерелгән түбәндәге язу урнашкан:

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕНӘ
ТАНЫКЛЫК

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К ГОСУДАРСТВЕННОЙ
НАГРАДЕ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Таныклык тышлыгының икенче ягында нинди дә булса язу юк.

Таныклык тышлыгының эчке ягына 2 форзац беркетелә һәм аңа җеп ярдәмендә ачык зәңгәр тангир челтәр фонындагы текстлы 8 өстәмә битле бланк беркетелә.

Өстәмә битләр бланкының беренче битендә өстә Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәте урнашкан, аның астында түбәндәге язу урнаштырыла:

* оешманы (оешма бүлекчәсен) бүләкләү турында документ сыйфатында файдалану өчен.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ БҮЛӘГЕНӘ
ТАНЫКЛЫК

УДОСТОВЕРЕНИЕ
К ГОСУДАРСТВЕННОЙ
НАГРАДЕ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

№

Өстәмә битләр бланкының икенче битендә түбәндәге язу урнаштырыла:

______________________________

(оешма (оешма бүлекчәсе)

______________________________

атамасы)

______________________________

Өстәмә битләр бланкасының өченче битендә түбәндәге язу урнаштырыла:

______________________________

______________________________

______________________________

бүләкләнде

Бүләк №

*Татарстан Республикасы*
*Президенты*

М.У.

**(Татарстан Республикасы Президентының Ф.И.А.и.)**

*Татарстан Республикасы*
*Президенты Указы*

**(Татарстан Республикасы Президенты Указы чыккан вакыт күрсәтелә)**

Өстәмә битләр бланкасының дүртенче битендә түбәндәге язу урнаштырыла:

______________________________

(наименование организации

______________________________

(подразделения организации)

______________________________

Өстәмә битләр бланкасының бишенче битендә түбәндәге язу урнаштырыла:

Награжден__

______________________________

______________________________

---

Награда №

*Президент*
*Республики Татарстан*

М.П.

**(Ф.И.О. Президента Республики Татарстан)**

*Указ Президента*
*Республики Татарстан*

**(указывается дата издания Указа Президента Республики Татарстан)**

Өстәмә битләр бланкасының алтынчы, җиденче, сигезенче битләрендә һәм арткы форзацта нинди дә булса язулар юк.

---

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Президентының
2010 елның 22 июнендәге
ПУ-396 номерлы Указына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы

______________________________
(район, шәһәр)

Оешманы (оешма бүлекчәсен) Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләүгә
**БҮЛӘКЛӘҮ КӘГАЗЕ**

______________________________
(Татарстан Республикасы дәүләт бүләге атамасы)

1. Оешма (оешма бүлекчәсе) атамасы ______________________________

______________________________
(татар* һәм рус телләрендә нигезләмә, оешманы (оешма бүлекчәсен) гамәлгә кую документлары нигезендә тутырыла)

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

2. Оешма (оешма бүлекчәсе) эшчәнлегенең төп төре (төрләре)______________________________

______________________________

______________________________

______________________________

3. Оешу вакыты ______________________________

4. Оешманың (оешма бүлекчәсенең) булган бүләкләре, бүләкләнүләре төрләре______________________________

5. Юридик адресы, элемтәгә керү өчен телефон

6. Бүләкләүгә тәкъдим ителүче оешма (оешма бүлекчәсенә) характеристика

(Татарстан Республикасы алдындагы казанышларын (ирешкән уңышларын), производстводагы, фәндәге

башка уңышларын күрсәтеп, ирекле формада тутырыла

Үтенечнамә кузгаткан орган җитәкчесе

(орган атамасы, вазыйфасы күрсәтелә)

имза Ф.И.А.и.

М.У.

Бәяләмә** ______________________________________________________________

(орган, оешма атамасы күрсәтелә)

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________________________

______________________________________________

житәкче имзасы Ф.И.А.и.

М.У. 20___ елның «______» __________________

___________

Искәрмәләр:

* Оешма (оешма бүлекчәсе) турында нигезләмәдә, аның гамәлгә кую документларында оешманың атамасы татар телендә күрсәтелгән очракта.

** Бүләкләү кәгазе кәгазь нөсхәдә бирелгән очракта тутырыла.

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Президентының
Рәхмәт сүзе турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

Татарстан Республикасы

______________________________
(район, шәһәр)

**Орган (оешма) коллективын Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән бүләкләүгә гариза кәгазе**

1. Коллективы бүләкләүгә тәкъдим ителүче орган (оешма) атамасы____________________

______________________________________________________________________________

(татар* һәм рус телләрендә орган, оешма турында нигезләмә, аның гамәлгә кую документлары,

______________________________________________________________________________

физик затны шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәве турында таныклыгы нигезендә тутырыла)

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

2. Коллективы бүләкләүгә тәкъдим ителүче оешма эшчәнлегенең төп төре (төрләре)**

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

3. Оешу вакыты ______________________________________________________________

4. Орган (оешма) коллективының булган бүләкләре, бүләкләнү төрләре________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

______________________________________________________________________________

5. Юридик адресы, элемтәгә керү өчен телефон

6. Бүләкләүгә тәкъдим ителүче орган (оешма) коллективына характеристика

(Татарстан Республикасы алдында казанышларын (ирешкән уңышларын), производстводагы, фәндәге

башка уңышларын күрсәтеп, ирекле формада тутырыла)

Үтенечнамә кузгаткан орган (оешма) җитәкчесе

(орган (оешма) атамасы, вазыйфасы күрсәтелә)

имза Ф.И.А.и.

М.У.

Бәяләмә***

(орган атамасы күрсәтелә)

җитәкче имзасы Ф.И.А.и.

М.У. 20___ елның «______» __________________

Бәяләмә***

(орган атамасы күрсәтелә)

__________________________________________________

житәкче имзасы Ф.И.А.и.

М.У. 20___ елның «______» ____________________

____________

Искәрмәләр:

* Орган, оешманың атамасы нигезләмәдә, аның гамәлгә кую документларында татар телендә күрсәтелгәндә, Россия Федерациясе гражданы паспортына гражданның шәхесе турында татар телендә мәгълүматлы өстәмә бит булганда.

** Бүләкләүгә оешма коллективы тәкъдим ителгән очракта тутырыла.

*** Гариза кәгазе кәгазь нөсхәдә бирелгән очракта тутырыла.

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Президентының
Рәхмәт сүзе турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

**Орган (оешма) коллективын Татарстан Республикасы Президенты Рәхмәт сүзе белән бүләкләү турындагы үтенечнамәгә теркәп бирелә торган документлар* исемлеге**

1. Нигезләмә, устав, башка гамәлгә кую турында документ, физик затны шәхси эшкуар сыйфатында дәүләт теркәве турында таныклыкның дәүләт органы, җирле үзидарә органы, оешма, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме, атасының исеме турында мәгълүматны үз эченә алган битләре күчермәсе.

2. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органын, үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) территориясендә тормышка ашыручы оешма, шәхси эшкуар (алга таба – оешмалар) коллективын Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе (алга таба – Рәхмәт сүзе) белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы бәяләмәсе**.

3. Үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә тормышка ашыручы оешма коллективын Рәхмәт сүзе белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – оешма коллективының Татарстан Республикасы алдында казанышлары (ирешкән уңышлары) булган өлкәдә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы республика башкарма хакимияте органы бәяләмәсе** (түбәндәге очраклардан кала:

оешма коллективының Рәхмәт сүзе белән бүләкләнергә мөмкин булган эшчәнлеге республика башкарма хакимияте органы идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы өлкәгә карамаганда;

Рәхмәт сүзе белән бүләкләү турында үтенечнамә оешма коллективының Рәхмәт сүзе белән бүләкләнергә мөмкин булган

казанышлары (ирешкән уңышлары) булган өлкәдә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы республика башкарма хакимияте органы тарафыннан кузгатылганда).

4. Орган, оешма коллективын Рәхмәт сүзе белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда:

а) үтенечнамә кузгатылган ел алдыннан килгән соңгы өч елда һәм агымдагы елның узган айларында орган, оешманың төп финанс-икътисадый күрсәткечләре динамикасы турында белешмә;

б) салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау турында белешмә;

в) хезмәт хакы түләү буенча бурычлары булмау турында белешмә;

г) үтенечнамә кузгатылган ел алдыннан килгән соңгы өч елда һәм агымдагы елның узган айларында җитештерүдә җәрәхәтләр очраклары турында Россия Федерациясе Мәҗбүри социаль иминиятләштерү фонды тарафыннан бирелгән белешмә.

5. Табигатьтән файдалану оешмасы коллективын Рәхмәт сүзе белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – табигатьтән файдалануның тиешле өлкәсендә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы республика башкарма хакимияте органының оешма тарафыннан табигатьтән файдалану өлкәсендә законнарның үтәлеше турында белешмә.

6. Юбилей датасы уңаеннан Рәхмәт сүзе белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – архив белешмәсе.

---

Искәрмәләр:

* Документлар ел дәвамында гамәлдә дип санала.

** Бәяләмә Рәхмәт сүзе белән бүләкләү турында үтенечнамә, гариза кәгазе һәм әлеге Исемлекнең 1, 4-6 пунктларында каралган документлар нигезендә аларны теркәү көненнән соң 30 календарь көн эчендә әзерләнә.

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
5 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе тасвирламасы**

1. Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе (алга таба – Рәхмәт сүзе) гражданнарны бүләкләгәндә китап бите юнәлешендә, кысага, пыяла астына куела торган А4 форматындагы (210 х 297 мм) тыгыз кәгазь битеннән гыйбарәт.

Кәгазь битенең алгы ягында периметр буенча бит кырыеннан 9 мм ара калдырып, 9 мм киңлектәге кыса эчендә алтынсу төстәге рельефлы-кабарынкы бизәк урнаштырылган.

Рәхмәт сүзе тексты саклык өчен тангир челтәр фонында, кәгазь битенең кырыеннан 25 мм аралык калдырып куелган куе көрән төстәге кыса эченә урнаштырыла.

Өске якта уртада югарыгы кырыйдан 38 мм арада алтынсу төстәге кабарынкы бизәк рәвешендә эшләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән.

Уртада аста Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан 15 мм арада бер юлда 4 мм биеклектәге алтынсу төстәге кабарынкы хәрефләр белән басылган «Президент Республики Татарстан» һәм «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләре урнашкан. Баш хәрефнең биеклеге 6 мм.

Уртада аста «Татарстан Республикасы Президенты» юлыннан 24 мм ераклыкта 10 мм биеклегендә алтынсу төстәге кабарынкы баш хәрефләр белән басылган «Рәхмәт сүзе» сүзләре урнаштырылган.

Астарак 5 мм биеклегендәге (баш хәрефе) һәм 2 - 3 мм биеклегендәге (юл хәрефе) кара төстәге хәрефләр белән Рәхмәт сүзе тексты басыла.

Тексттан астарак уртада Татарстан Республикасы Президентының герблы мөһере куелган имзасы һәм Татарстан Республикасы Президентының исеме инициалы, атасының исеме инициалы һәм фамилиясеннән торган имзаны шәрехләү урнашкан, алар 5 мм биеклегендәге (баш хәрефе) һәм 3 мм биеклегендәге (юл хәрефе) кара төстәге хәрефләр белән басылган.

Астарак уртада 3 мм биеклегендәге (баш хәрефе) һәм 2 мм биеклегендәге (юл хәрефе) кара хәрефләр белән басылган «Казан, Кремль» сүзләре һәм дата урнаштырыла.

Барлык язулар һәм Рәхмәт хаты тексты ике дәүләт теленең берсендә: рус яисә татар телендә эшләнә.

Рәхмәт сүзе белән чит ил гражданы, гражданлыксыз затлар бүләкләнгәндә, барлык язулар һәм Рәхмәт сүзе тексты чит телдә башкарылырга мөмкин.

2. Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе органнар, оешмалар коллективларын бүләкләгәндә альбом бите юнәлешендә урнашкан, кысага, пыяла астына куела торган А3 форматындагы (297 х 420 мм) тыгыз кәгазь битеннән гыйбарәт.

Кәгазь битенең алгы ягында периметр буенча бит кырыеннан 10 мм аралык калдырып, 10 мм киңлектәге кыса эчендә алтынсу төстәге рельефлы-кабарынкы бизәк урнаштырылган.

Рәхмәт сүзе тексты саклык өчен тангир челтәр фонында һәм кәгазь битенең кырыеннан 25 мм арада куелган куе көрән төстәге кыса эченә урнаштырыла.

Өске якта уртада югарыгы кырыйдан 45 мм арада алтынсу төстәге рельефлы-кабарынкы бизәк рәвешендә эшләнгән Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтләнгән. Астарак битнең аскы кырыеннан 27 мм арада Казан Кремленең бер төстәге кабарынкы сурәте урнаштырылган.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан өстә сул һәм уң якта бер юлда 4 мм биеклектәге алтынсу төстәге кабарынкы хәрефләр белән басылган «Президент Республики Татарстан» һәм «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләре урнашкан. Баш хәрефнең биеклеге 5 мм.

Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан сулда, астарак «Президент Республики Татарстан» юлыннан 10 мм арада 9 мм биеклектәге алтынсу төстәге кабарынкы баш хәрефләр белән басылган «БЛАГОДАРНОСТЬ» сүзе урнаштырылган. Татарстан Республикасы Дәүләт гербыннан уңда «Татарстан Республикасы Президенты» юлыннан 10 мм арада 9 мм биеклектәге алтынсу төстәге кабарынкы баш хәрефләр белән басылган «РӘХМӘТ СҮЗЕ» сүзләре урнаштырылган.

Астарак кара төстәге хәрефләр белән 5 мм биеклегендәге (баш хәрефе) һәм 2 - 3 мм биеклегендәге (юл хәрефе) Рәхмәт сүзе тексты басыла, сулда – рус телендә, уңда – татар телендә.

Тексттан астарак уртада Татарстан Республикасы Президентының герблы мөһере куелган имзасы һәм Татарстан Республикасы Президентының исеме инициалы, атасының исеме инициалы һәм фамилиясеннән торган имзаны шәрехләү урнашкан, алар 5 мм биеклегендәге (баш хәрефе) һәм 3 мм биеклегендәге (юл хәрефе) кара төстәге хәрефләр белән басылган, өстә – рус телендә, аста – татар телендә.

Астарак 3 мм биеклегендәге (баш хәрефе) һәм 2 мм биеклегендәге (юл хәрефе) кара хәрефләр белән басылган «Казан, Кремль» сүзләре һәм дата урнаштырыла, сулда – рус телендә, уңда – татар телендә.

Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт сүзе белән чит ил дәүләтләре дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм чит ил һәм халыкара оешмалары коллективлары бүләкләнгәндә, Рәхмәт сүзе тиешле чит

телдән файдаланып башкарылырга мөмкин. Бу очракта рус һәм татар телләрендәге язмалар – сулда, чит телдәге язмалар уңда башкарыла.

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
6 нчы кушымта

Татарстан Республикасы
дәүләт бүләкләре белән
бүләкләү турында үтенечнамәләрне
карау тәртибенә
1 нче кушымта

**Гражданны Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамәгә теркәп бирелә торган документлар* һәм белешмәләр исемлеге**

1. Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү хакында үтенечнамә кузгатылган граждан паспортының аның шәхесе турында татар һәм рус телләрендәге мәгълүматлы битләре күчермәсе (татар телендә – Россия Федерациясе гражданы паспортына гражданның шәхесе турында татар телендәге мәгълүматлы өстәмә бит булганда).

2. Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамәләр Татарстан Республикасы оешмалары, җәмәгать берләшмәләре коллективлары, Татарстан Республикасы авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары тарафыннан кузгатылганда:

а) Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләнү турында үтенечнамә кузгатылган гражданның Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләнергә лаек булырлык эшчәнлекне тормышка ашыру урыны буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы бәяләмәсе** (гражданның Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләнергә лаек булырлык эшчәнлеге Татарстан Республикасы территориясендә башкарылмау очракларыннан тыш);

б) гражданның Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләнергә лаек казанышлары (ирешкән уңышлары) булган өлкәдә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы республика башкарма хакимияте органы бәяләмәсе** (түбәндәге очраклардан кала:

гражданның Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләнергә лаек булырлык эшчәнлеге республика башкарма хакимияте органы идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы эшчәнлек өлкәсенә карамаганда;

Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә гражданның Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләнүгә лаек казанышлары (ирешкән уңышлары) булган өлкәдә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы республика башкарма хакимияте органы тарафыннан кузгатылганда;

Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда).

3. Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә дәүләт органы, Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) җирле үзидарә органы тарафыннан кузгатылганда – әлеге Исемлекнең 2 пункты «б» пунктчасында каралган бәяләмә.

4. Татарстан Республикасы дәүләт бүләге – «Татарстан Республикасында җирле үзидарәне үстерүдәге казанышлар өчен» медале белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләр советы бәяләмәсе**.

5. Оешма җитәкчеләрен, аларның урынбасарларын, оешманың баш инженерларын, баш бухгалтерларын һәм баш икътисадчыларын Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда:

а) үтенечнамә кузгатылган ел алдыннан килгән соңгы өч елда һәм агымдагы елның узган айларында оешманың төп финанс-икътисадый күрсәткечләре динамикасы турында белешмә;

б) салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау турында белешмә;

в) хезмәт хакы түләү буенча бурычлары булмау турында белешмә;

г) үтенечнамә кузгатылган ел алдыннан килгән соңгы өч елда һәм агымдагы елның узган айларында җитештерүдә җәрәхәт алу очраклары турында Россия Федерациясе Социаль иминиятләштерү фонды тарафыннан бирелгән белешмә.

6. Табигатьтән файдалану оешмасы җитәкчеләрен, аларның урынбасарларын Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – табигатьтән файдалануның тиешле өлкәсендә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы республика башкарма хакимияте органының оешма тарафыннан табигатьтән файдалану өлкәсендә законнарның үтәлеше турында белешмә.

7. Җирле үзидарә органы җитәкчесен Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – тиешле муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый үсеше төп күрсәткечләре.

8. «Татарстан Республикасының Халык артисты», «Татарстан Республикасының Халык язучысы», «Татарстан Республикасының Халык шагыйре», «Татарстан Республикасының Халык рәссамы», «Татарстан Республикасының Атказанган артисты», «Татарстан Республикасының Атказанган сәнгать эшлеклесе» дигән Татарстан Республикасы мактаулы исемнәрен бирү турында үтенечнамәләр кузгатылганда:

а) Татарстан Республикасының тиешле иҗат берлеге бәяләмәсе (Татарстан Республикасының тиешле иҗат берлеге булган очракта);

б) язылган әсәрләре, уйнаган рольләре, куелган спектакльләре, афиша концертларында һәм спектакльләрендә башкарылган төп партияләре, уздырылган шәхси күргәзмәләре исемлеге;

в) иҗат эшчәнлеге турында массакүләм мәгълүмат чараларында басылган мәкаләләр (тулаем эшчәнлеге чорында яисә, элек мактаулы исем бирелгән булса, шуннан соңгы эшчәнлеге чорында);

г) Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылган гражданның фотографиясе.

9. «Татарстан Республикасының Атказанган архитекторы» дигән Татарстан Республикасы мактаулы исеме бирү турында үтенечнамә кузгатылганда – Татарстан Республикасы Архитекторлар берлеге бәяләмәсе һәм иҗади эшләре исемлеге.

10. «Татарстан Республикасының Атказанган фән эшлеклесе» дигән Татарстан Республикасы мактаулы исеме бирү турында үтенечнамә кузгатылганда:

а) фәнни һәм фәнни-гамәли эшчәнлеге нәтиҗәләрен тану турында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы бәяләмәсе;

б) гыйльми дәрәҗәләре һәм гыйльми исемнәре турында дәүләт үрнәгендәге документлар күчермәсе;

в) фәнни хезмәтләре исемлеге (автордашлары булганда – аңа карата Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылган гражданның шәхси өлешен күрсәтеп);

г) аңа карата Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылган гражданның эшчәнлеге турында ул хезмәткәр булып тормаган кимендә ике югары уку йортының бәяләмә-үтенечнамәсе.

11. «Татарстан Республикасының Атказанган уйлап табучысы» һәм «Татарстан Республикасының Атказанган рационализаторы» дигән Татарстан Республикасы мактаулы исемнәрен бирү турында үтенечнамә кузгатылганда:

а) Татарстан Республикасы Уйлап табучылар һәм рационализаторлар җәмгыяте бәяләмәсе;

б) кулланууга кертелгән уйлап табулары һәм гамәлгә ашырылган рационализаторлык тәкъдимнәре исемлеге.

12. «Татарстан Республикасының Атказанган матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр хезмәткәре» дигән Татарстан Республикасы мактаулы исеме бирү турында үтенечнамә кузгатылганда – Татарстан Республикасының тиешле иҗат берлеге бәяләмәсе (Татарстан Республикасының тиешле иҗат берлеге булган очракта).

---

Искәрмәләр:

* Документлар ел дәвамында гамәлдә дип санала.

** Бәяләмә Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә, бүләкләү кәгазе һәм әлеге Исемлекнең 1, 5-12 пунктларында каралган документлар нигезендә аларны теркәү көненнән соң 30 календарь көн эчендә әзерләнә.

Татарстан Республикасы
Президенты указларына
кертелә торган үзгәрешләр
исемлегенә
7 нче кушымта

Татарстан Республикасы
дәүләт бүләкләре белән
бүләкләү турында үтенечнамәләрне
карау тәртибенә
2 нче кушымта

**Оешманы (оешма бүлекчәсен) Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамәгә теркәп бирелә торган документлар* һәм белешмәләр исемлеге**

1. Оешма, оешма бүлекчәсе (алга таба – оешма) уставының, гамәлгә кую турында башка документның, нигезләмәнең оешма атамасы турында мәгълүматлы битләре күчермәсе.

2. Үз эшчәнлеген Татарстан Республикасы муниципаль районы (шәһәр округы) территориясендә тормышка ашыручы оешманы Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – Татарстан Республикасының тиешле муниципаль районы (шәһәр округы) башлыгы бәяләмәсе**.

3. Оешманың Татарстан Республикасы социаль-икътисадый үсешенә керткән өлеше турында белешмә.

4. Үтенечнамә кузгатылган ел алдыннан килгән соңгы биш елда һәм агымдагы елның узган айларында оешманың төп финанс-икътисадый күрсәткечләре динамикасы турында белешмә.

5. Салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмау турында белешмә.

6. Хезмәт хакы түләү буенча бурычлары булмау турында белешмә.

7. Үтенечнамә кузгатылган ел алдыннан килгән соңгы биш елда һәм агымдагы елның узган айларында җитештерүдә җәрәхәтләр алу очраклары турында Россия Федерациясе Мәҗбүри социаль иминиятләштерү фонды тарафыннан бирелгән белешмә.

8. Үтенечнамә кузгатылган ел алдыннан килгән соңгы биш елда һәм агымдагы елның узган айларында Татарстан Республикасы территориясендә социаль әһәмияткә ия чараларны тормышка ашыру, шул исәптән хәйрия эшчәнлегендә катнашу турында белешмә.

9. Архитектура, мәдәният һәм сәнгать, массакүләм мәгълүмат чаралары өлкәсендә үз эшчәнлеген тормышка ашыручы оешманы Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – Татарстан Республикасының тиешле иҗат берлеге бәяләмәсе (Татарстан Республикасының тиешле иҗат берлеге булган очракта).

10. Фәнни оешманы Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – фәнни һәм фәнни-гамәли эшчәнлеге нәтиҗәләрен тану турында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президиумы бәяләмәсе.

11. Табигатьтән файдалану оешмасын Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – табигатьтән файдалануның тиешле өлкәсендә идарә функцияләрен (функцияләрне җайга салу) тормышка ашыручы республика башкарма хакимияте органының оешма тарафыннан табигатьтән файдалану өлкәсендә законнарның үтәлеше турында белешмә.

12. Мобилизация эше алып баручы оешманы Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – мобилизация эшенең һәм планлаштыру документларын әзерләү буенча эшнең барышы турында белешмә.

13. Юбилей датасы уңаеннан Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә кузгатылганда – архив белешмәсе.

Искәрмәләр:

* Документлар ел дәвамында гамәлдә дип санала.

** Бәяләмә Татарстан Республикасы дәүләт бүләге белән бүләкләү турында үтенечнамә, бүләкләү кәгазе һәм әлеге Исемлекнең 1, 3-13 пунктларында каралган документлар нигезендә аларны теркәү көненнән соң 30 календарь көн эчендә әзерләнә.